МИНИСТЕРСТВО
ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

26.12.2022 г. Казань № под-2293/22

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 27.02.2015 ел, № 1156/15 боерыгы белән расланган Аерым предметлар тирәнтен өйрәнүле төп гомуми һәм урта гомуми белем яисә профиль белем алу өчен Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль мәгариф оешмаларына кабул иткәндә яисә күчергәндә укучыларны индивидуаль сайлап алуны оештыру тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Б о е р а м:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 27.02.2015 ел, № 1156/15 боерыгы белән расланган Аерым предметлар тирәнтен өйрәнүле төп гомуми һәм урта гомуми белем яисә профиль белем алу өчен Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль мәгариф оешмаларына кабул иткәндә яисә күчергәндә укучыларны индивидуаль сайлап алуны оештыру тәртибенә (Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 12.03.2021 № под-334/21 боерыгы белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Укучыларга, аларның ата-аналарына (законлы вәкилләренә) гаризалар бирү вакыты һәм индивидуаль сайлап алу процедурасы турында мәгълүмат бирү индивидуаль сайлап алу башланганчы 30 көннән дә соңга калмыйча рәсми сайт, укучылар һәм ата-аналар җыелышлары, мәгълүмати стендлар, массакүләм мәгълүмат чаралары аша гамәлгә ашырыла.

Индивидуаль сайлап алу үткәрелә:

аерым уку предметларын тирәнтен өйрәнү дәресләренә яңа уку елына күчергәндә бер гомуми белем бирү оешмасы чикләрендә-агымдагы уку елының 1 апреленнән 15 июненә кадәр;

яңа уку елына бер гомуми белем бирү оешмасыннан икенчесенә аерым уку предметлары тирәнтен өйрәнелә торган сыйныфларга күчергәндә – агымдагы уку елының 1 апреленнән 15 июленә кадәр, шуннан соң кабул итүче гомуми белем

бирү оешмасына яңа уку елының 1 сентябреннән кабул итеп;

профильле сыйныфларда урта гомуми белем алу өчен кабул ителгәндә - календарь елның 20 июненнән 31 августына кадәр чорда, аннары, яңа уку елының 1 сентябреннән башлап, кабул итүче гомуми белем бирү оешмасының 10 сыйныфына кабул итеп.

Индивидуаль сайлап алу турында гаризаны карау срогы гариза биргән көннән алып 30 көннән артмаска тиеш.»;

8 нче пунктны «индивидуаль сайлап алу башланганчы 40 эш көненнән дә соңга калмыйча» сүзләре белән тулыландырырга;

14 нче пунктны түбәндшге редакциядә бәян итәргә:

«14. Комиссия карары турында белем бирү оешмасы укучыларга, аларның ата-аналарына (законлы вәкилләренә) тиешле предмет яки профиль буенча комиссия беркетмәгә кул куйганнан соң өч эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр итәргә тиеш.»;

28 нче пункт үз көчен югалткан дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Мәгариф өлкәсендә күзәтчелек һәм контроль департаментының Аналитик, мәгълүмати һәм оештыру ягыннан тәэмин итү бүлегенә (Л.И. Саубанова) әлеге боерыкны билгеләнгән срокта Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрүне тәэмин итәргә.

Министр И.Г.Һадиуллин